ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 с.Старое Дрожжаное № 262

Муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану өчен торглар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 13 сентябрендәге 398 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (17.10.2022 № 533, 12.09.2023 № 364 редакциясендә), муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану өчен торглар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының **2.8.2.1 пунктының 8 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән төзелгән килешүдә каралган территория чикләрендә урнашкан, әлеге җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, аларда урнашкан бүлмәләр, төзелеп бетмәгән объект хуҗасы, яки мондый җир кишәрлегенә карата хокук иясе җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов